КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 22 гыйнвар г.Казань № 22

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү турында» 2020 ел, 10 апрель, 267 нче карары белән расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү бирү тәртибенә һәм шартларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү турында» 2020 ел, 10 апрель, 267 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 10 сентябрь, 823 нче; 2020 ел, 5 ноябрь, 999 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Өч яшьтән җиде яшькә кадәрге (җиде яшьне кертеп) балага айлык акчалата түләү бирү тәртибенә һәм шартларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә.

2.1 пунктның икенче абзацына «аны билгеләү турындагы гаризаның бертип формасын» сүзләреннән соң «(алга таба – гариза)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле $2.1^1$ пункт өстәргә:

«$2.1^1$. Әгәр дә гариза бирүче һәм (яки) аның ире (хатыны) Россия Федерациясенең җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, федераль куркынычсызлык хезмәте органнары, дәүләт саклау органнары, Россия Федерациясенең эчке эшләр органнары хезмәткәре булса, гариза бирүче гариза белән бергә әлеге Тәртипнең һәм шартларның 3.6 пунктындагы икенче, өченче, сигезенче

абзацларында каралган керемнәрнең булуын һәм күләмен раслый торган документларны Үзәк бүлегенә тапшыра.

Әгәр дә гариза әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән зат (затлар) тарафыннан «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы) яки Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын файдаланып бирелгән булса, гариза бирүче гариза биргән көннән биш эш көне эчендә Үзәк бүлегенә әлеге Тәртипнең һәм шартларның 3.6 пунктындагы икенче, өченче, сигезенче абзацларында каралган, әлеге затларның керемнәре булуын һәм күләмен раслый торган документларны тапшыра.»;

2.4 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гариза бирүче тарафыннан әлеге Тәртипнең һәм шартларның 2.1 и $2.1^1$ пунктлары нигезендә документларның тапшырылмавы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин